КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 август г.Казань № 1011

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган архив документлары милкен аеру һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган, Татарстан Республикасының дәүләт милкенә караган архив документларын исәпкә алуны тәэмин итү турында» 2007 ел, 28 май, 203 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган архив документлары милкен аеру һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган, Татарстан Республикасының дәүләт милкенә караган архив документларын исәпкә алуны тәэмин итү турында» 2007 ел, 28 май, 203 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 6 август, 624 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 685 нче; 2016 ел, 27 июнь, 444 нче; 2016 ел, 10 ноябрь, 836 нчы; 2017 ел, 12 сентябрь, 650 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 774 нче; 2018 ел, 2 октябрь, 897 нче; 2019 ел, 13 сентябрь, 826 нчы; 2020 ел, 10 сентябрь, 672 нче; 2021 ел, 16 август, 734 нче; 2022 ел, 18 август, 858 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм муниципаль архивларда саклана торган архив документлары милкен аеру һәм муниципаль архивларда саклана торган, Татарстан Республикасының дәүләт милкенә караган архив документларын исәпкә алуны тәэмин итү турында»;

әлеге карарга 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карарга 3 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2010 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасы дәүләт милкенә кертелгән документларны саклый торган муниципаль архивлар исемлеге, урман хуҗалыкларының һәм Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы дәүләт системасына караган башка оешмаларның Татарстан Республикасы дәүләт милкенә кертелгән муниципаль архивларда саклана торган делолары саны»;

әлеге карарга 4 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2015 елның 1 гыйнварына карата Татарстан Республикасы дәүләт милкенә кертелгән документларны саклый торган муниципаль архивлар исемлеге, Татарстан Республикасы үзәк район һәм участок хастаханәләренең, территориаль медицина берләшмәләре һәм шифаханәләренең Татарстан Республикасы дәүләт милкенә кертелгән муниципаль архивларда саклана торган делолары саны».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 28 май, 203 нче
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 24 август, 1011 нче
карары редакциясендә)

2023 елның 1 гыйнварына карата муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган документларны саклый торган Татарстан Республикасы муниципаль архивлары исемлеге һәм Татарстан Республикасы муниципаль архивларында саклана торган һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган эшләр, шулай ук 2007 – 2022 елларда муниципаль архивларны туплау чыганаклары булган муниципаль архивларга саклауга кергән Татарстан Республикасы учреждениеләре делолары саны

| Т/с | Муниципаль архив исеме | Делолар саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7 705 |
| 2. | Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7 174 |
| 3. | Аксубай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7 636 |
| 4. | Актаныш муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 4 646 |
| 5. | Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 5 821 |
| 6. | Әлки муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 3 786 |
| 7. | Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 13 222 |
| 8. | Апас муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 4 726 |
| 9. | Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару бүлеге | 7 190 |
| 10. | Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 2 471 |
| 11. | Баулы муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 7 006 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 12. | Балтач район башкарма комитетының архив бүлеге | 4 349 |
| 13. | Бөгелмә муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 13 505 |
| 14. | Буа муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 10 715 |
| 15. | Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 4 963 |
| 16. | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5 585 |
| 17. | Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 3 656 |
| 18. | Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 13 212 |
| 19. | Зәй муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 8 162 |
| 20. | Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 17 594 |
| 21. | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 1 835 |
| 22. | Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 5 576 |
| 23. | Кукмара муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5 797 |
| 24. | Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 6 263 |
| 25. | Лениногорск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 9 238 |
| 26. | Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 8 955 |
| 27. | Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4 241 |
| 28. | Минзәлә муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5 209 |
| 29. | Мөслим муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 4 365 |
| 30. | «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге архивы» муниципаль казна учреждениесе | 10 171 |
| 31. | Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 2 552 |
| 32. | Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 6 254 |
| 33. | Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 5 586 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 34. | Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4 041 |
| 35. | Саба муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 4 634 |
| 36. | Сарман муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5 728 |
| 37. | Спас муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 8 136 |
| 38. | Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 8 170 |
| 39. | Тукай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5 465 |
| 40. | Теләче муниципаль районы башкарма комитетының архив эше секторы | 2 018 |
| 41. | Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 5 050 |
| 42. | Чистай муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 11 917 |
| 43. | Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының архив бүлеге | 3 221 |
| 44. | Яр Чаллы шәһәре башкарма комитеты эш башкару идарәсенең архив бүлеге | 19 991 |
| 45. | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының муниципаль архив идарәсе | 18 796 |
| | Барлыгы | 326 333 |